

2024 елнын беренче яртыеллыгына «Юлдаш» газетасына язылу тәмамланганчы аз вакыт калып бара. Барлык даими абонентларыбыз киләсе елда да безнен белән калырлар дип ометләнәбез. Бәлки, яна укучылар да табарбыз.
Без киләсе елда да лаеклы кешеләр һәм вакыйгалар турында мәкаләләр һәм рәсемнәр бастырачакбыз, торак пунктлар тарихы, милли-мәдәни иҗтимагый тормыш турында сойләячәкбез, безнен тобәктә туган атаклы татарлар белән таныштырачакбыз. Шулай ук юбилейлар һәм башка моһим даталар белән котлауларыгызны да бастырып чыгарачакбыз. Татарларыбызнын матур эшләре, милли жанлы кешеләребез турында да әйтәсе килә. Мәсәлән, газетабызны яратып укучы, аны очен жан атучы Дубенка районы Ломат туган ягы тамырларыннан аерылмаган Новокузнецк шәһәре “Чулпан” мәчете имам-хатыйбы Анвәр хазрәт Аширов vзенен акчасына якташларына “Юлдаш” газетасын яздырып куйган. Шундый ел саен яздыручыларыбыз безнен бар. Алар – гомеренен кvп олешен Мордовия предприятиеләрендә директорлык эшенә багышлаган, Россия сәнәгатьчеләр һәм эшмәкәрләр берлеге идарәсе әгъзасы, Россия Федерациясенен Атказанган машина тозvчесе, “Якташлар” татар тобәк милли-мәдәни автономиясе идарәсе әгъзасы Камиль Шәvкәт улы Мангутов, ООО “ТД “ЭКО халял” директоры Талип Рафаил улы Абубекиров, Чамзинка районы главасы Руслан Альфред улы Батеряков һәм башкалар, һәм башкалар.
“Әгәр дә сез конvзәк мәсьәләләр белән бергә, татар доньясындагы моһим вакыйгалар турында хәбәрдар булырга теләсәгез, кичекмәстән „Юлдаш“ басмасына язылыгыз”, - дип чакырабыз.
“Юлдаш” - сезнен газета, Мор-довиянен хормәтле татарлары! Безнен язылу индексы ПР729.